| СОВЕТ БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2024 елның 12 январы** Бишня ав. **№ 171**

Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советының 20.12.2021 №64 карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлеше) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Бишнә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Бишнә авыл җирлеге Советының 20.12.2021 №64 карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлеше) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Җыенда кабул ителгән карар муниципаль хокукый акт булып тора, җирлек башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертелергә тиеш (19 нчы кушымта).»;

1.2. 4.7 пунктта «(№19, №20 кушымтасы)» сүзләрен алып ташларга;

1.3. 19 нчы кушымтаны яңа редакциядә, әлеге карарның 1 нче кушымтасына ярашлы рәвештә, бәян итәргә;

1.4. 20 нче кушымта алып ташларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Бишнә авыл**
**җирлеге башлыгы, Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**

Бишнә авыл җирлеге
Советының 12.01.2024 №171
карарына1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Зеленодольск
муниципаль районы Бишнә авыл
җирлеге Советының 20.12.2021ел №64
карарына19 нчы кушымта

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең _______________ торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

__________ 20__ №___

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «__» ___ 20__ ел 00 сәгать 00 минутта («__» ______ 20__ ел 00 сәгать 00 минутта) гражданнар җыены беркетмәсе (гражданнарның этаплап җыеннары нәтиҗәләре белән) түбәндәге мәсьәлә буенча тәзелде ___________________________________________________
« ӘЙЕ» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы ___ кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны __ кеше, бу ___% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучылар__ тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучылар ___ тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең _____ торак пунктында гражданнар җыены узган дип танылсын, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танылсын.

2. Мәсьәлә буенча карарны таныргa: «2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге _______ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш ___ сум күләмендә үзара

салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1) _____________;

2) _____________ кабул ителгән дип танырга.

3. ____ елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән ____ сум күләмендә үзара салым кертергә.

4. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: ____________________________________________________________

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче _____________